КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 173

Яңа Чишмә муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 8 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан 0,1462 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен кушымта нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 28 февраль, 173 нче
карарына кушымта

Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерелә торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мәйданы, гектар | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 16:31:090202:573 | 0,04 | Яңа Чишмә |
| 16:31:090202:574 | 0,0139 | |
| 16:31:090202:575 | 0,0523 | |
| 16:31:090301:316 | 0,0071 | |
| 16:31:090301:317 | 0,0329 | |
| Барлыгы | 0,1462 | |

___________________________